| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«18» март 2025г. № 48

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 06 октябрендәге 257 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында.

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538 номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комтеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 06 октябрендәге 257 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (26.08.2022 № 164, 14.11.2022 № 249, 13.09.2023 № 138, 31.01.2024 № 15, 06.03.2024 № 33, 02.10.2024 № 122, 09.12.2024 № 156 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) күрсәтелгән карарның 1.3 пункты белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ реглмаентына:

- 2.8.2.1 пунктның 13 пунктчасында «бастырылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин